Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы Карары

14.05. 2021 ел № 25

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018елның 15 декаберендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 29.12.2017 ел, № 463-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 84 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хөснетдинов

СОВЕТ ВЕРХНЕСЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1610000506

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының
2021 елның «15» декабрь № 84 номерлы
карарына 1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018елның 15 декаберендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 84 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 статьяның 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

« җирлекнең генераль планына, шәһәр округының Генераль планына үзгәрешләр әзерләү очракларыннан тыш, территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителү белән бәйле җәмәгать тыңлаулары яисә гавами тыңлаулар, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин».